Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлеше - Дорожная урамы гражданнарның җыены нәтиҗәләре турында

ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

8 ноябрь 2025 ел № 1

2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче статьясы нигезендә, 2025 елның 8 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта узган «Сез Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлешендә - Дорожная урамында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2026 елда 4400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп, түбәндәге эшләр:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту белән килешәсезме

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 23 (егерме өч) катнашучы кертелгән, 13 (унөч) кеше гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашкан, бу 56,5% ны тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен гражданнар җыенының 13 (унөч) катнашучысы тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлеше - Дорожная урамы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес, дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең «Каменка» шифаханәсе поселогы торак пункты территориясенең бер өлеше - Дорожная урамы яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2026 елда 4400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районың интернет челтәрендәге рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Ф. Нуруллин